МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.12.2014 г. Казань № 7301/14

**Каюм Насыйри исемендәге премия бирү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 нче елның 19 нчы июненнән һәм 2010 нчы елның 30 нчы декабреннән кабул ителгән "Каюм Насыйри исемендәге премия турында"гы 396 һәм 1141 нче санлы карарлары нигезендә педагогик коллективларга, мәктәпкәчә белем бирү, гомуми урта, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә ел саен Каюм Насыйри исемендәге премия бирелә.

Премия милли мәгарифне үстерүдә һәм Татарстан Республикасы халыклары милли мәдәниятенең традицияләренә таянып, белем һәм тәрбия бирүдә яхшы нәтиҗәләргә ирешкән, милли белем оешмалары өчен укыту-методик кулланмалар һәм фәнни хезмәтләр язган өчен билгеләнә.

2014 нче елда Каюм Насыйри исемендәге премиягә 13 эш кабул ителде. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 27 нче ноябреннән 6749/14 нче боерыгы нигезендә тәкъдим ителгән кандидатураларның эшчәнлеге комиссия тарафыннан өйрәнелде. Каюм Насыйри исемендәге премия билгеләү буенча комиссия утырышы үткәрелде. Яшерен тавыш бирү юлы белән Каюм Насыйри исемендәге премиягә лауреатлар сайланды һәм комиссия карары кабул ителде.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге премия билгеләү комиссиясе нәтиҗәләренә нигезләнеп, БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Каюм Насыйри исемендәге премияләрне түбәндәге педагогик коллективларга һәм аерым шәхесләргә бирергә:

- Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе коллективына;
- «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 10 нчы номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе коллективына;
- Казан шәһәре Совет районының «20 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе директоры Арсланова Рәхимә Минвәли кызына;

- Яр Чаллы шәһәре «29 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Исхакова Рима Мөхәррәм кызына.

2. Лауреатларга «Каюм Насыйри исемендәге бүләк» билгесен тапшырырга.

3. 2014 нче ел өчен Каюм Насыйри исемендәге премиягә тәкъдим ителгән хезмәткәрләрнең һәм коллективларның нәтиҗәле эшен билгеләп үтәргә, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломы белән бүләкләргә (1 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының исәп-хисап бүлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 30 нчы декабреннән кабул ителгән «Каюм Насыйри исемендәге премия турында»гы 1141 нче номерлы карарына нигезләнеп, лауреатларга премия бирергә.

5. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән министры

Э.Н. Фәттахов

Р.М. Фәхриева
294-95-10

*1 нче кушымта*

2014 нче ел өчен Каюм Насыйри исемендәге премиягә тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге

| | |
|---|---|
| | **Коллективлар исемлеге** |
| 1 | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Гомуми үсеш төрендәге «Алтынчәч» балалар бакчасы» коллективы |
| 2 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең «Шатлык» 1 нче баланың аң-белемен үстерү үзәге» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениеесе коллективы |
| 3 | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "1 нче Арча балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем биру учреждениеесе коллективы |
| 4 | «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 10 нчы номерлы гимназия" Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеесе коллективы |
| 5 | Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә белем бирүче 3 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениеесе коллективы |
| 6 | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе» муниципаль гомуми белем учреждениеесе коллективы |
| | **Аерым шәхесләр исемлеге** |
| 1 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениеесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сәрвәрова Рәдинә Миңнерәсил кызы |
| 2 | «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Әйшә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениеесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Бачкова Эльвира Василий кызы |
| 3 | Казан шәһәре Совет районының «20 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениеесе директоры Арсланова Рәхимә Минвәли кызы |
| 4 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ризванова Альбина Габдрахман кызы |
| 5 | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре «29 нчы гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Исхакова Рима Мөхәррәм кызы |
| 6 | Татарстан Республикасы Зәй шәһәренең 6 нчы урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гыйльманова Гөлнара Рәвеф кызы |
| 7 | Татарстан Республикасы «Биектау муниципаль районының 1 нче номерлы Биектау урта гомуми белем мәктәбе» филиалы – «Учхоз гомуми белем мәктәбе»нең математика, физика һәм информатика укытучысы Гариф Нурулла Гыйматдин улы |